СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

____________________ с. Сарманово №________________

**03.09.2015 ел 205 номерлы карар**
**Авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башкарма комитетының вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдим кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башкарма комитетының вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка һәм Сарман авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1-2 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә;

- Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының карар проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Совет рәисе урынбасары Г.Р.Гәрәева